КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.09.2025 № 447-П

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Архангельский тыкрыгы, 1 адресы буенча урнашкан «Зилант монастыре», 1681 ел, XVIII – XIX гасырлар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты турында белешмәләрне төгәлләштерү хакында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2025 елның 12 августындагы уңай бәяләмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Архангельский тыкрыгы, 1 адресы буенча урнашкан «Зилант монастыре», 1681 ел, XVIII – XIX гасырлар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты турында белешмәләрне әлеге боерык кушымтасына туры китереп төгәлләштерергә.
2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын саклау
комитетының 2025 елның 15
сентябрендәге 447-П номерлы
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Архангельский тыкрыгы, 1 адресы буенча урнашкан «Зилант монастыре», 1681 ел, XVIII – XIX гасырлар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты турында төгәлләштерелә торган белешмәләр

1. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Архангельский тыкрыгы, 1 адресы буенча урнашкан «Зилант монастыре», 1681 ел, XVIII – XIX гасырлар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты турында белешмәләргә төгәллек кертеп, аның атамасын «Успение Зилант монастыре»на үзгәртергә.

2. «Успение Зилант монастыре», 1681 ел, XVIII – XIX гасырлар мәдәни мирас объекты составындагы региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары турында белешмәләрне төгәлләштерергә:

| № | Объектның исеме | Объектны төзү датасы, объектны төп үзгәртү (үзгәртеп кору) даталары | Объектның урнашу урыны | Объектның тарихи-мәдәни әһәмияте категориясе | Объектның төре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Успение Зилант монастыре | 1681 ел, XVIII – XIX гасырлар | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Архангельский тыкрыгы, 1 | региональ әһәмияттәге | ансамбль |
| 2 | Барлык Изгеләр чиркәве | 1681 ел | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Архангельский тыкрыгы, 1 | региональ әһәмияттәге | һәйкәл |
| 3 | Настоятель корпусы | 1808 ел | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Архангельский тыкрыгы, 1 | региональ әһәмияттәге | һәйкәл |